КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 24 декабрь г.Казань № 1285

2022 – 2028 елларга Татарстан Республикасында кеше хокуклары буенча стратегияне раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2022 – 2028 елларга Татарстан Республикасында кеше хокуклары буенча стратегияне (алга таба – Стратегия) расларга.

2. Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары Татарстан Республикасы дәүләт программаларын формалаштырганда һәм тормышка ашырганда, шулай ук Татарстан Республикасы законнары проектларын һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларын әзерләгәндә Стратегия нигезләмәләренә таянып эш итәргә.

3. Стратегия чараларын тормышка ашыруда катнашучы Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары җитәкчеләренә ел саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 10 ысына кадәр, кушымтада бирелгән форма буенча аларның үтәлеше турындагы хисапны, ярты елга бер тапкыр, хисап чорыннан соң килә торган айның 10 ысына кадәр, Стратегиянең 8 бүлеге чараларын үтәү турындагы хисапны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына кертергә.

4. Түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

Стратегия чараларын тормышка ашыруда катнашучы федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм оешмаларга ел саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 10 ысына кадәр, кушымтада бирелгән форма буенча аларның үтәлеше турындагы хисапны, ярты елга бер тапкыр, хисап чорыннан соң килә торган айның 10 ысына кадәр, Стратегиянең 8 бүлеге чараларын үтәү турындагы хисапны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына кертүне;

Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә ел саен Татарстан Республикасында кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен саклау

турында ясала торган докладта Стратегия чараларын тормышка ашыру турындагы мәгълүматны чагылдыруны.

5. Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән Стратегия чаралары исемлеген тормышка ашыруга бәйле чыгымнар тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

6. 2022 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасында кеше хокуклары буенча стратегияне раслау турында» 2014 ел, 2 август, 569 нчы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2018 елларга Татарстан Республикасында кеше хокуклары буенча стратегияне раслау турында» 2014 ел, 2 август, 569 нчы карары белән расланган 2014 – 2018 елларга Татарстан Республикасында кеше хокуклары буенча стратегиягә үзгәрешләр кертү хакында» 2016 ел, 22 декабрь, 973 нче;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2018 елларга Татарстан Республикасында кеше хокуклары буенча стратегияне раслау турында» 2014 ел, 2 август, 569 нчы карары белән расланган 2014 – 2018 елларга Татарстан Республикасында кеше хокуклары буенча стратегиягә үзгәрешләр кертү хакында» 2017 ел, 14 ноябрь, 874 нче;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2018 елларга Татарстан Республикасында кеше хокуклары буенча стратегияне раслау турында» 2014 ел, 2 август, 569 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 ел, 5 февраль, 72 нче.

7. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин